РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422053, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Евлаштау, ул. Ш.Бариева, д.23
тел. (84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422053, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Явлаштау авылы, Ш.Бариев урамы, 23 йорт
тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
25.09.2018 г.

КАРАР
№16

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Явлаштауавыл жирлегендә гражданнардан үзара
салым акчасы җыю һәм аны куллану буенча жирле
референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында” 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, “Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында” 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының “Жирле референдум турында” 24.03.2004 №23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштауавыл жирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Явлаштауавыл жирлеге Советының 24.09.2018 №15 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары, Явлаштауавыл жирлеге башкарма комитетының 24.09.2018 №30 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштауавыл жирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштауавыл жирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча жирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Жирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Явлаштауавыл жирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

– Явлаштауавылында жирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;
– Мишәбаш авылында жирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү;

ӘЙЕ　　　　　　　　　　ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм жирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Явлаштауавыл жирлеге башлыгы　　　　　　　　Р.Х.Нуриев